**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә 2024 елда үзара салым (бер тапкыр түләнә торган түләүләр) чараларын кертү турында**

# КАРАР

2023 елның «14» ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 36, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 24, 35 статьялары, Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 28.04.2020 ел, №5 номерлы карары белән кабул ителгән, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 11, 16, 44, 89 статьялары нигезендә, Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 09.10.2020 ел, № 7 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында» нигезләмәсе, 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә үзара салым чараларын (бер тапкыр түләүләрне) кертү соравы буенча гражданнар җыенының беренче, икенче, өченче, дүртенче, бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче, тугызынчы, унынчы, унберенче, уникенче, унөченче, ундүртенче, унбишенче, уналтынчы, унҗиденче, унсигезенче, унтугызынчы, егерменче этаплары нәтиҗәләре турында» 14.11.2023 ел, №1 карары белән, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыены карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан тыш, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балачак инвалидларыннан, 1,2 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, Чернобыль АЭСында авария ликвидаторларыннан һәм аңа тиңләштерелгән категориядәге гражданнардан тыш, үзара салымны 400 сум күләмендә кертергә һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган көндезге уку рәвешендә укучы

студенттан 200 (ике йөз) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләнә торган түләү) кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы зираты территориясен төзекләндерү - "МХО зонасында һәлак булганнар истәлегенә Дан аллеясы төзү".

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының бюджет-финанс комиссиясенә йөкләргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Урыссу шәһәр
тибындагы поселогы Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин